| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КУАКБАШСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«КУАКБАШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2026 елның 6 апреле № 11

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы 18 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының түбәндәге карарларының үз көчен югалтуын танырга:

18.12.2014 №35 «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау турында»;

01.06.2022 №13 Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 декабрендәге 35 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәгә үзгәреш кертү турында»;

от 19.10.2023 №38 Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2014 елның 18 декабрендәге 35 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль

хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында».

2.Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы , Куакбаш авылы, К. Маркс урамы 15 йорт жирле үзидарә бинасында, Сходнево-Чертанлы авылы Ирек урамы 5Б йорт авыл клубы бинасында, Чуте авылында Тынычлык урамындагы 8А йорт авыл клубында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) "Авыл жирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

4.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Куакбаш авыл җирлеге»
муниипаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.Р.Әхмәтҗанова